Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының утыз җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

7 декабрь, 2023 ел № 287

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру барышы турында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының авыл территорияләрен комплекслы үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Программаны үтәүчеләргә алга таба гамәлгә ашыру барышында бюджеттан тыш чыганаклар өлешендә программа чараларын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү эшен активлаштыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов